МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.09.2022 Казан ш. № 866

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуына эшкә алучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясының 3 пунктына нигезләнеп, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуына эшкә алучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмә (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе турында» 2017 елның 20 июлендәге 477 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 20 июлендәге 477 номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау

министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 29 апрелендәге 310 номерлы.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.Ф.Вәлиулловка йөкләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 15 сентябрендә 866 номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуына эшкә алучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә эшкә алучы вәкиленнән – Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрыннан (Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – Министр) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба, туры китереп – Министрлык, граждан хезмәткәре) түләүсез нигездә коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуына (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән Министрлыкта оештырылган беренчел һөнәри оешманың сайлаулы органы белән идарә итү катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) (алга таба – коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашу) рөхсәт алу тәртибен билгели.

2. Граждан хезмәткәренең коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яки вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималына китермәскә тиеш.

3. Коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуга Министр рөхсәтен алу язмача формада гариза бирү юлы белән гамәлгә ашырыла, аның киңәш ителә торган үрнәге әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

4. Гариза гражданлык хезмәткәре тарафыннан Министрлыкның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затына (алга таба – җаваплы зат) коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнаша башлаганчы тапшырыла.

5. Җаваплы затка гариза биргәнче, граждан хезмәткәре үзе гражданлык хезмәтен уза торган Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесенә, таныштырып чыгу һәм граждан хезмәткәре коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималлыгының булуы турында аның фикерен алу өчен, шәхсән гариза җибәрә.

6. Гариза җаваплы затка кергән көнне гаризаларны теркәү журналында теркәлә, аның киңәш ителә торган үрнәге әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган.

Теркәү турындагы тамга белән гаризаның күчермәсен җаваплы зат граждан хезмәткәренә ул алынган көнне гаризаларны теркәү журналында кул куйдыртып тапшыра яисә почта аша, тапшыру турында белдерү белән җибәрә.

7. Җаваплы зат гаризаны беренчел карый һәм аңа карата граждан хезмәткәренең коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашу мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында мотивацияләнгән бәяләмә (алга таба - мотивацияле бәяләмә) әзерли.

Мотивацияле бәяләмәне әзерләгәндә җаваплы зат гариза тапшырган граждан хезмәткәренең ризалыгы белән аның белән әңгәмә уздыра, аннан язмача аңлатмалар ала ала.

8. Мотивацияле бәяләмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) гаризада бәян ителгән мәгълүмат;

б) граждан хезмәткәре граждан хезмәтен уза торган Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесенең граждан хезмәткәре коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгының барлыкка килү ихтималлыгының булуы турындагы фикере;

в) гариза тапшырган граждан хезмәткәре белән әңгәмә вакытында алынган мәгълүмат (булган очракта);

г) граждан хезмәткәре тарафыннан гаризага язма аңлатмада (булган очракта) бирелгән мәгълүмат;

д) гаризаны алдан карау нәтиҗәләре буенча мотивлаштырылган нәтиҗә.

9. Гариза һәм аңа карата мотивацияле бәяләмә гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көне эчендә җаваплы зат тарафыннан карар кабул итү өчен Министрга җибәрелә.

10. Гариза һәм аңа карата мотивацияле бәяләмә, Министр резолюциясе нигезендә, дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия утырышында гариза тапшырган граждан хезмәткәрендә шәхси кызыксынучанлык һәм, ул коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта, мәнфәгатьләр каршлыгы барлыкка килү ихтималлыгы булуы предметына карап тикшерелә.

11. Гаризаны, аңа карата мотивацияле бәяләмәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министр тарафыннан карар кабул ителгән вакыттан башлап өч эш көне эчендә җаваплы зат, граждан хезмәткәренең вакытлыча хезмәткә сәләтсез булу, отпуск ялында, хезмәт командировкасында булу чорын, хөрмәткә лаек сәбәпләр аркасында аның хезмәттә булмый торган башка очракларны исәпкә алмыйча, граждан хезмәткәренә язмача формада Министр кабул иткән карар турында хәбәр итә.

12. Гариза, аңа карата мотивацияле бәяләмә һәм гаризаны карауга бәяле башка материаллар (алар булган очракта) граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 15 сентябрендә 866 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуына эшкә алучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

____

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

______________________________________
(инициаллар, фамилия)

кемнән
______________________________________
(вазыйфа атамасы)

______________________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

Коммерциясез оешма белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга рөхсәт бирү турында гариза

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктының «б» пунктчасы нигезендә миңа коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм

__________________________________________________________________________
(коммерциясез оешманың оештыру-хокук формасын һәм атамасын, адресын, эшчәнлек төрләрен күрсәтергә)

__________________________________________________________________________

Коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашу хезмәттән буш вакытта башкарылачак һәм мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә яисә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималына китереп чыгармаячак.

________________ ______________________ «____» _____________ 20___ ел.
(имза) (тулы имза)

Таныштым _______________________________________________________
(министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесенең граждан хезмәткәре, коммерциясез

__________________________________________________________________________

оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта, хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималлыгы турындагы фикере)

___________________________________________________________________________

_______________________________________ _______________________________________
(Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесе вазыйфасының исеме, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)) (имза, дата)

Гаризаларны теркәү журналында теркәлү номеры

Гаризаны теркәүгә алу датасы

________________________________
(белдерүне теркәгән затның имзасы)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 15 сентябрендә 866 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуына эшкә алучы вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

## Коммерциясез оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен гаризалар теркәү журналы

| т/с | Гаризаның теркәү номеры | Гаризаны теркәүгә алу датасы | Гаризаның кыскача эчтәлеге | Гариза тапшыручы затның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), вазыйфа аталышы | Гаризаны кабул итүче затның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), вазыйфа аталышы | Гаризаның күчермәсен алу турында (күчермәсен алдым, гариза тапшырган затның имзасы) яки гаризаның күчермәсен почта аша җибәрү турында тамга | Гаризаны Министрга тапшыру турында тамга | Кабул ителгән карар турында тамга |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | |